ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КОРНОУХОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Корноухово авылы 14.03.2018 №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Корноухово авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль-шәхси хезмәттәшлек өлкәсендә аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органын билгеләү турында

2015 елның 13 июнендәге “Россия Федерациясендә дәүләти-шәхси хезмәттәшлек, муниципаль-шәхси хезмәттәшлек һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” гы 224-ФЗ номерлы Федераль законның 18 маддәсенең 2 өлешенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Корноухово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 43 маддәсенә туры китереп һәм җирлек икътисадына инвестицияләр җәлеп итү өчен хокукый шартлар булдыру һәм, кулланучыларны алар белән тәэмин итүне оештыру җирле үзидарә органнары карамагындагы мәсьәләләр булып торганлыктан, товарларның, эш, хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын күтәрү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге Башкарма комитетын (килештерү буенча) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “ Корноухово авыл җирлеге” мунииципаль берәмлегенең түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга вәкаләтле җирле үзидарә органы итеп билгеләргә:

1) муниципаль-шәхси хезмәттәшлек проектын тормышка ашырганда җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең ярашканлыгын тәэмин итү;

2) муниципаль-шәхси хезмәттәшлек турында килешү төзүгә хокукка конкурслар үткәрү өчен ачык хезмәттәшнең конкурс документларын килештерү;

3) муниципаль-шәхси хезмәттәшлек турында килешүне тормышка ашыруның мониторингын гамәлгә ашыру;

4) муниципаль-шәхси хезмәттәшлек турында килешүне тормышка ашыру процессында ачык хезмәттәшләрнең һәм хосусый хезмәттәшләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауда булышлык итү;

5) муниципаль-шәхси хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләр реестрын алып бару;

6) муниципаль-шәхси хезмәттәшлек турындагы килешүләр хакында мәгълүматның ачыклыгын һәм, кереп, аннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү;

7) муниципаль-шәхси хезмәттәшлек турындагы килешүне тормышка ашыру мониторингы нәтиҗәләрен вәкаләтле органга тәкъдим итү;

8) 2015 елның 13 июнендәге "Россия Федерациясендә дәүләти-шәхси хезмәттәшлек, муниципаль-шәхси хезмәттәшлек һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" гы 224-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Корноухово авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставында һәм муниципаль хокукый актларда каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Корноухово авылы, Совхоз урамы, 8 нче йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Корноухово авыл җирлеге башлыгы В.В Колчанов